

Кечкенә авыл һәм поселоклар очен производство яшәешне анлата. Кая ул бар – халык яши. Илнен светотехник отраселе авыр Боек Ватан сугышыннан сонгы елларда аякка баса башлады. Шул вакыт Мордовия индустриаль мәйдан дип сайланды да. 1965 елдан эшли башлаган ОАО «Кадошкинский электротехнический завод»ы продукцияләре бvген дә Калининградтан Владивостокка кадәр билгеле. КЭТЗда 524 кеше хезмәт итә. Ул - цех эшчеләре, администрация, инженерлар, конструкторлар... Алар арасында татар милләтле кешеләребез байтак. Шуларнын берничәсе турында сvз барыр.
АО «КЭТЗ» (АО «Кадошкинский электротехнический завод»)нын топ байлыгы - эшчеләре. Алар очен завод чын-чыннан туган йортка әйләнгән; эшләре бурыч кына тvгел, ә гомерлек хезмәт булган.        Ин яхшы бригадаларнын берсе - пускорегулирующий аппаратлар жыючы слесарь-электромонтажниклар. Бригада ай саен планын 100дән артык процентка vти, югары сыйфатлы продукция чыгара. Бригадиры Валентина Ивановна Москаева ин яхшы, булдыклы, ихтирамга лаеклы эшчеләре арасында тумышы белән Инсар районы Яндовище авылыннан  Клара Айса кызы Ахметованы атый. Югары кvрсәткечләре билгеләнеп бырыла, ди.
Кадошкино заводы лампочкалары Индия һәм башка илләрдә дә яна, дидек. Бу унышларда милләттәшләребезнен керткән олешләре зур.Озак еллар мактаулы хезмәткәрләр арасында тумышлары белән Иса (Большие Поляны) авылыннан Рәшит Шәvкәт улы Зайкин, Венера Назыйф кызы Долотказина, Рива Аббяс кызы Резакова, Римма Мехаммәтша кызы Кильдеева, Латышовкадан Рифат Амин улы Талдытов, Алсу ханым Безрукова һәм башкалар тырышып эшлиләр.
АО «Кадошкинский электротехнический завод»ынын  Хезмәт ветераннары оешмасында 457 кеше. Югары класслы профессионал турында берничә сvз. Бvген 36 ел стажлы Валерий Рауф улы Долотказин 1980 елда завод проходноен беренче тапкыр vтә. Хәзер производство хормәтлеләренен берсе ул. Унышлары очен кырык ел эш стажы булган укытучысы Геннадий Алексеевич Паршуткинга рәхмәтле. Валерий Рауф улы укытучысы турында болай ди: «Нигездә, - ди ул, - зур хәреф белән язылган Мастернын урта сәләтле укучылары булмый! Белеме очен рәхмәтлемен. Укытучынын кvрсәткән хезмәте укучысынын vзеннән артык белvе генә тvгел, укучысынын инструментальщиклар коллективынын традицияләрен vтәвендә дә кvренә. Аларга чынлыклылык, vти торган

эшенне 
жиренә житкереп башкару, анын очен жаваплылык тәрбияләде наставнигым. Коллективтагы, элеккесендә һәм бvгенгесендә, климат  та башкалардан аермалы – безнен участок житәкчеләрнен һәрвакыт аерым кvзәтvе астында тора».
В.Р.Долотказиннын Хезмәт книжкасында бары бер язу саклана - АО «Кадошкинский электротехнический завод»)нын инструменталь участогы. Башта шлифовальный микронный (тогәллелек һәм сыйфатлылык) станогында миллиметрга, йозләгән олешенә дә ялгышырга ярамаган участокта бар кочен хезмәтенә биреп эшли. Бvгенге техника меннәр олешенә кадәр тогәл булырга момкинлек бирә. Ун елдан артык инде Валерий Рауф улы югары сыйфатлы продукция булдыру очен электроэрозийный станок артында стандартлар таләп иткән штампны vти. Нәтижәдә - югары сыйфатлы светильник жыела. Әйтеп китәргә кирәк, Долотказиннар гаиләсе - электротехниклар династиясе. Валеранын әтисе Рауф Ариф улы бу заводта  инженер-конструктор булып озак еллар хезмәт итә. Сәләтле инженер, эшенә ижади якын килә иде дип язалар житәкчеләре истәлекләрендә. Тагы әнисе - Валентина Михайловна шул ук производствода секретарь-машинистка булып хезмәт итә. Долотказиннар династиясен Валеранын тормыш иптәше Людмила Юрьевна тулыландыра. Бу династиянен хезмәт стажы 150 елга якын. Элек жырларда жырланганча- семья заводская, зур ихтирам казанган династия.
Жыю цехы слесарь-электромонтажниклар бридадасы да мактаулылар рәтендә. Тату коллективта Татьяна Кобелькова, Любовь Гришакина, Галина Селиванова, Светлана Кузенкова, Лариса Федосеева, Любовь Клешина, Татьяна Уткина, Валентина Палаткина белән бергә тумышы белән Латышовка авылыннан Надия ханым Байчурина эшли. Аларнын биографияләре завод белән аерылгысыз, жилкәләрендә производствоны тоталар. Бу бригада белән завод горурлана. Бvгенге эшсезлек вакытында биредә тырыш кешеләргә урын житә, дип белдерә бригадиры Татьяна Кобелькова. Заводта 37 яшьлекләргә кадәр 30%  яшь буын хезмәт итә.
Кадошкино электротехник заводы  кешеләре һәрвакыт эштә генә тvгел, спортта да vзләрен сынатмаганнар. Предприятиядә эш һәм спорт бергә vскәннәр. Спортка багышланган чаралар һәрвакыт заводчыларнын кvнелләренә хуш килә. Торле район һәм республика кvләмендә йогерv, чанга ярышлары, футболда профессионаллар буларак тvгел, ә спортны яратучылар буларак унышларга ирешәләр.
Менә шулай тырыш татарлары белән производство яши.

Наилә Насырова